РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
МАЛОБУИНКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР БУАСЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

18 июль 2022 ел. № 49-1

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Татар Буасы авыл җирлегендә бюджет процессы
турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлеге Советы,

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2018 елның 14 июлендәге 51-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Татар Буасы авылы җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә (12.05.2020 № 84-1, 19.08.2020 № 90-1, 20.10.2020 № 4-1, 15.09.2021 № 26-1, 13.10.2021 № 29-1, 08.04.2022 № 42-1 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 16.1 статья:

4 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Субсидияләр бирелгәндә, аларны бирүне җайга сала торган муниципаль хокукый актларга керүче мәҗбүри шарт булып, субсидияләр алучының, субсидияләр алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның аларны тикшерүгә карата, бюджет чараларын алучы буларак, субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәүче буларак баш күрсәтмә бирүче тарафыннан, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүгә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268_1 һәм 269_2 статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәүне һәм шундый нигезләмәләрне килешүгә кертүгә ризалыгы тора (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән тыш, устав (тупланма) капиталларында, коммерция оешмалары катнашында аларның устав (тупланма) капиталларында шундый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында).».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм җирлекнең рәсми сайтында Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы Татар Буасы
авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Йосыпов